**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА МЕНЗЕЛИНСКА МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИНЗӘЛӘ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 10.09.2025

КАРАР
№ 423

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының

"Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлеге, Заводская урамы, 2В йорты адресы буенча урнашкан, 8576 кв.м мәйданлы, кадастр номеры 16:28:180108:100 булган җир участогын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә - "складлар" җитештерү зонасында (ПК) боерыгы проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына, Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципләры турында» Федераль законына, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына ярашлы, Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Минзәлә муниципаль районы, "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлеге җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча "җитештерү зонасында складлар" - 16:28:180108:100 кадастр номеры белән, мәйданы 8576 кв.м булган җир участогын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә. Адресы: Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлеге, Заводская урамы, 2В йорты.

2. Ачык тыңлауларны оештыручы составын - коллегиаль киңәшмә органын расларга:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Чухланцев Д.А.;

Минзәлә муниципаль районының "ПИЗО" МКУ рәисе Шакиров Р.С.;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы урынбасары - баш архитектор Петров В.К.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы Басков Е. А.,

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының юридик сектор мөдире Петрова А.В.

3. Ачык тыңлауларны оештыручыга ачык тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм

уздыруны тәэмин итәргә.

4. Ачык тыңлауларны үткәрү чорын билгеләү – 2025 елның 17 сентябреннән 10 октябренә кадәр. Ачык тыңлауларны үткәрү вакыты 2025 елның 14 октябренә кадәр.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Шәйсуваров